ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 13.12.2022 КАРАР

1639

2023 елның 1 яртыеллыгына торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондына караган торак урыннарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәренең торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондына караган торак урыннарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү

ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен расларга (1 нче кушымта).

2. 2023 елның 1 гыйнварыннан Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елның 2 яртыеллыгына торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондына караган торак урыннарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2022 елның 3 июнендәге 699 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш һәм гамәлдә булу чоры 2023 елның 1 гыйнварыннан башлап барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабугга муниципаль районы
Башкарма комитетының
20__ елның__¬¬¬_ _____ _____
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондына караган торак урыннарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак урыннарны карап тотуга 2023 елның 1 гыйнварыннан түләү күләме**

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Түләү алынучы үлчәнеш берәмлеге (айга), сум. | Күрсәтелгән хезмәтнең үлчәнеш берәмлеге буенча тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2023 ел-30.06.2023 ел |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 4,06 |
| **2** | Уртак милек составына керүче гомуми файдалану урыннарын, шулай ук җир участогын санитар яктан карап тоту, шул исәптән: | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | **24,95** |
| | -гомуми файдалану урыннарын җыештыру; | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 3,44 |
| | - йорт яны территориясен җыештыру | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 4,62 |
| | - чүп чыгару торбасын карап тоту; | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 3,25 |
| | - дератизация | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 0,20 |
| | - торак биналарның конструктив элементларын агымдагы | торак урынның гомуми мәйданының | 2,89 |

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Түләү алынучы үлчәнеш берәмлеге (айга), сум. | Күрсәтелгән хезмәтнең үлчәнеш берәмлеге буенча тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2023 ел-30.06.2023 ел |
| | ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | 1 кв.м. | |
| | - йорт эчен су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 2,39 |
| | - үзәк җылытуның йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 2,39 |
| | - йорт эчендәге электр челтәрләренә һәм җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 1,03 |
| | -йорт эчендәге газ белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 0,40 |
| | - йорт эчендәге вентиляцион (җилләтү) каналларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 0,27 |
| | -1 каттан башлап лифтларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 4,07 |
| 4 | Гомумйорт газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 21,53 |
| 5 | Наем өчен түләү (яллаучылар өчен) | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 6,38 |